## Татарстан Республикасы
## Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә  авыл җирлеге Советы

### КАРАР

«08» июль 2025 ел № 117

Олы Әтнә авыл җирлеге Советының 31.05.2013 елның 69/1 номерлы  «Олы Әтнә авыл җирлегенең муниципаль милке белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» гы карарын үз көчен югалткан дип тану турында.

2024 елның 27 декабрендәге Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитеты вәкаләтләренең бер өлешен Әтнә муниципаль районының милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына тапшыру турында төзелгән килешүгә таянып, Татарстан Республикасы Әтнә районы прокуратурасының 11.06.2025 елгы №02-08-03-2025 күрсәтмәсе нигезендә, Олы Әтнә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Олы Әтнә авыл җирлеге Советының 31.05.2013 елгы 69/1 номерлы  «Олы Әтнә авыл җирлегенең муниципаль милке белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында»гы  карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм интернет челтәрендә (http://atnya.tatarstan.ru ) адресы буенча бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Олы Әтнә авыл җирлеге
советы рәисе урынбасары: Маликова Р.Р.